| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2017 Казан ш. № 7-7/т

Әлмәт ш. «Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланууда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 07 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт ш. «Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланууда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә шушы карар кушымтасына туры китереп, чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланууда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү турында» 02.03.2016 № 7-3/т карарының 1 пунктының көчен югалтуын танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 24.11.2017 № 7-7/т карарына кушымта

Әлмәт ш. «Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдалануда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар

1 бүлек. Чик дәрәҗә максималь тарифлар

| № п/п | Хезмәтләр төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф, сумнарда (НДС исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Әлмәт маневрлы районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 20,87 |
| 2. | Түбән Кама маневрлы районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 16,52 |
| 3. | Түбән Кама нефть базасы кишәрлеге буенча 1 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 4,62 |
| 4. | Алан (Алан ст.) маневрлы районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 43,09 |

2 бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгый тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләргә I «Чик дәрәҗә максималь тарифлар» бүлегендә каралмаган тарифлар Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы боерыгы белән расланган Сәнәгый тимер юл транспортында башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләргә тарифлар һәм җыемнар формалаштыру буенча методик күрсәтмәләр нигезендә якларның килешүендә билгеләнә.

2. Йөк ташу һәм төяп җибәрү-бушату эшләре өчен түләү заказчыдан ташылган йөкнең фактик авырлыгы өчен алына.

3. Йөк ташу буенча түләү алу өчен ераклык, төгәл санга түгәрәкләп, километрларда билгеләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге